**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Кызыл Бакча торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19.11.2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 19.11.2020 елда үткәрелгән йомгаклау беркетмәсе киләсе сораулар буенча төзелде «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән сез 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?

- Кызыл Бакча торак пунктында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау, (төзелеш материаллары сатып алу, мемориаль плитәләр, буяу, брусчатка, пьедесталны ремонтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 66 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 59 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 59 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен берседә бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны кабул итәргә: «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән сез 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?

- Кызыл Бакча торак пунктында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау, (төзелеш материаллары сатып алу, мемориаль плитәләр, буяу, брусчатка,

пьедесталны ремонтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү)» кабул ителгән дип санарга.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча авылында мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru)да кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлек башлыгы Р. Ә. Кәримов